СОВЕТ ПОДЛЕСНО-
ШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ
АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**

Урман Асты
Шонталасы ав.

**КАРАР**

**04.08.2023** **№ 38**

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190 – ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 06 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 1 өлешендәге 20 пунктына таянып,

**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы карар итте:**

1.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре турында» 2013 елның 1 июлендәге 56 номерлы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Урман Асты Шонталасы авылының үзәк өлешендә, атап әйткәндә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге, Урман Асты Шонталасы авылы, Карл Маркс урамы, 15А йорт, ОД1 территориаль зонаның бер өлеше (күп функцияле иҗтимагый-эшлекле зона) Ж1 территориаль зонасына үзгәртелде (шәхси торак төзелеше зонасы). Үзгәртелгән территориаль зонаның гомуми мәйданы 2315 м. кв. тәшкил итә.

Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган җир участокларының кадастр номерлары: 16:05:140101:280.

Әлеге территориаль зонаның кадастр кварталы: 16:05: 140101

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга https://alekseevskiy.tatarstan.ru.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.
4. Карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль**
**районының Урман Асты**
**Шонталасы авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.Ә.Җиһаншин**